• МИНБӘР •
ЧЫН МӘХӘББӘТ НИДӘН ГЫЙБАРӘТ?
*4 бит*

• СОРАУ-ҖАВАП •
ИЗГЕ ГАМӘЛЛӘР ИМАНГА КЕРӘМЕ?
*7 бит*

• НӘСЫЙХӘТ •
«ЯРАМЫЙ»ДАН БАШЛАРГА ЯРАМЫЙ!
*12 бит*

• ӘДӘБИ СӘХИФӘ •
Ә СИН ЫШАНАСЫҢМЫ?
*14 бит*

*№ 8 (301)* | *Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы* | *мөхәррам 1442*

*Август, 2020*

# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ




*Дәвамы 2 нче биттә*

# Татарстан мөфтиенең һиҗри исәп буенча яңа ел башлану уңаеннан мөрәҗәгате



**Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим! Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтул-лаһи вә бәрәкәтүһ!**

**Кадерле дин кардәшләрем! Газиз милләттәшләрем!**

Мөхәррам аеның беренче көнендә (20 август) бөтен мөселман дөньясы һиҗри буенча яңа 1442 елны каршы алды. Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте исеменнән һәм шәхсән үзем сезне шушы күркәм дата белән ихластан тәбриклим!

Мөселман календаренең башлангыч ноктасы булып кешелек тарихында иң мөһим вакыйгаларның берсе – Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең һиҗрәте тора. Һиҗрәт – пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм аның сәхабәләренең Мәккә-и Мөкәррәмәдән Мәдинә-и Мөнәүвәрәгә бөек күчеше ул. Моңа аларны мөшрикләрнең эзәрлекләүләре, кыерсытулары, мәрхәмәтсез җәберзолымнары мәҗбүр иткән. Ирекле рәвештә, бернинди чикләүләрсез, тыюларсыз һәм ачыктан-ачык хак динне – исламны тотуны ният итеп, 622 елның мөхәррам аенда Мәккәдәге мөселманнар үзләренең йортларын, каралты-кураларын, мөлкәтләрен, туган җирләрен ташлап чыгып китә. Нәкъ менә шушы күчеш аркасында бөек Ислам дине дөнья буйлап тарала башлаган.

Һиҗрәтнең Аллаһы ризалыгы өчен азатлыкка һәм дин иреген ирешү юлының башы булып торуында бернинди шик юк. Хактыр ки, аның максаты Ислам турында кешеләргә ишеттерү һәм тарату булган. Шушы изге ниятләр хакына Аллаһы Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм аның сәхабәләре үзләренең малмөлкәтләрен, ә кайберләре гомерләрен дә корбан иткәннәр. Шул рәвешле алар Аллаһы Тәгаләгә һәм Аның соңгы Шәригатенә үзләренең ихлас сөюләрен һәм тугрылыкларын белдергәннәр, киләчәк буыннарга маяк булып балкып торган үрнәк күрсәткәннәр. Мөэмин-мөселманнар һиҗри буенча яңа елны әнә шулай – Аллаһы Тәгаләнең Рәхмәтенә һәм Аның чиксез нигъмәтләренә шөкер кылып, сөекле Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм сәхабәләр каһарманлыгын олуглап каршылый. Дин кардәшләребез алдагы 12 айда иманнарын тагын да куәтләп, туры юлда игелекле гамәлләр кылып, Аллаһының ризалыгын һәм рәхмәтен алырга зур өметләр баглыйлар.

Мөселман календаре буенча яңа 1442 ел башлану алдыннан Раббыбыз һәр гаиләгә бәрәкәт ирештерүен, безнең игелекле гамәлләр кылу ниятләребезне тормышка ашыру өчен Үзенең хәер-фатихасын бирүен, илебезгә һәм республикабызга тынычлык, иминлек, бар мөселман өммәтенә бәрәкәт ирештерүен сорап догалар кылам. Әәмин.

■ **Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин**

# «Зәкят» хәйрия фонды «Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит» акциясен башлап җибәрде

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды ел саен үткәрелә торган «Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит» республикакүләм акциясе башлануы хакында игълан итә.

Акция кысаларында Татарстанның күп балалы, аз керемле һәм инвалид балалар тәрбияләнә торган гаиләләренә мәктәп кирәк-яраклары сатып алу өчен акча җыелачак. Мәктәп портфеле комплекты үзгәрешсез булып кала бирә: болар – канцелярия товарлары, дәфтәрләр, хезмәт һәм рәсем дәресләре өчен җыелмалар һәм башкалар.

Әгәр сезнең бу изге гамәлдә катнашасыгыз килсә, Сбербанк картасына 4817 7601 6652 0787 (Борһанова Майя Атамуратовна – «Зәкят» фонды хезмәткәре) акча җибәрә аласыз.

Безнең сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Яшермә, юкса Аллаһы Тәгалә сиңа бирергә мөмкин нәрсәләрне синнән яшерер, мөмкинлегеңә карап, Аллаһы юлында сарыф ит».

Аллаһы Тәгалә сезнең изге эшләрегезне кабуллардан кылсын!

■ **dumrt.ru сайтыннан**



# Кыйраәт белгечләрен әзерләү өчен махсус төркем тупланды



20 нче августта Татарстан мөселманнары Дfinия нәзарәте башлангычы белән Казанның Галиев мәчетендә Коръәннең ун кыйраәте буенча дәресләр башланды. Дәресләргә барлык таләпләргә җавап биргән 12 хафиз сайлап алынды – алар Коръәнне тулысы белән ятлаучылар һәм гарәп телен яхшы үзләштерүчеләр. Ун кыйраәтне өйрәнү дәресләрен алучы хафизлар арасында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да бар.

Беренче дәрескә килүчеләрне сәламләп, мөфти хәзрәт кыйраәтләрне өйрәнүнең әһәмиятенә тукталып үтте. Татар дин галиме Муса Җаруллаһ Бигиев үзенең «Коръән тарихы» дип исемләнгән китабында болай дип әйтә: «Минем өчен шунысы ачык ки: өммәтебезгә җиткерергә һәм дини мәктәпләрдә укытырга тиешле булган ислам фәннәреннән Коръән уку төрләре фәнен Әш-Шатыбиның «Әл-Касыйд» һәм Ибне Әл-Җәзариның «Тайиб» дәрәҗәсендә укыту тора, чөнки безне бу дөньяда һәм Ахирәттә бәхеткә илтә торган ислам диненең нигезе – ул Коръән. Шуңа күрә, безнең бурычыбыз – Коръән белән бәйле булган әйберләрне белергә омтылу». Муса Бигиев «һәрбер мәдрәсәдә һәр шәкерт иң ким дигәндә шатыбия дәрәҗәсендә булса да кыйраәтләрне белергә тиеш» булуын ассызыклап уза. Шатыбия – җиде кыйраәт буенча китап дигән сүз. Димәк, гади генә бер шәкерт җиде кыйраәтне белергә тиеш.

Дәресләрне Казан ислам университетының Коръән-хафизлар әзерләү үзәге мөгаллиме, Татарстандагы бердәнбер ун кыйраәт белгече Раушан хәзрәт Йосыпов алып бара. Ул Ливандагы Трипол шәһәренең Әл-Җинән университетында дүрт ел дәвамында белем алган һәм ун кыйраәт буенча иҗазәт алуга ирешкән. Аның чылбыры исә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә барып тоташа.

Раушан хәзрәт беренче дәресне ачып җибәреп, гыйлемнәрнең иң бөекләреннән Коръәнне һәм Коръән белән бәйле гыйлемнәрне өйрәнүне ассызыклап узды: «Коръән белән бәйле мөһим фәннәрнең берсе – кыйраәтләрне өйрәнү – ул безгә Коръәнне тәфсир һәм гарәп теле ягыннан яхшы аңларга булыша. Әлеге фәннең төп китабы булып «Шатыбия» тора». Ул күп илләрдә басыла. Нәзарәт тарафыннан Татарстанда кыйраәт белгечләрен әзерләү өчен «Шатыбия» китабының Казан басмасы файдаланылачак. Ул Казанда 1907 елда Муса Бигиев тарафыннан басмага әзерләнә һәм бертуган Кәримовлар типографиясендә басыла. Әлеге китапның репринт басмасы укучылар өчен махсус рәвештә нәзарәтнең «Хозур» нәшриятында янәдән бастырылды. «Шатыбия» китабының авторы имам Әш-Шатыби (һиҗри буенча 538 елда туган), аны җиңел ятлау һәм аңлау өчен, ул хезмәтен шигырь формасында язган. Шул рәвешчә әлеге китапны ятлау җиңел бирелә.

Раушан хәзрәт Йосыпов бүген ун кыйраәтнең укылышы бәян ителүче «Шатыбия» китабы буенча кереш дәрес үткәрде. Раушан хәзрәт әлеге фәнне өйрәнү өчен шәкертләрдән игътибарлылык, сабырлык кебек сыйфатлар кирәк булуын ассызыклап узды. Төп шартлар булып шулай ук хафиз булу һәм гарәп телен яхшы белү тора.

Кыйраәт буенча дәресләр якынча ике ел дәвам итәчәк.

Моңа кадәр татарстанлылар Коръәнне нигездә «Хафс ган Гасым» кыйраәте буенча укыйлар иде. Татарстанда кыйраәт белгечләрен әзерләп чыгару өчен махсус төркем булдыру Коръән буенча белемнәрне тирәнәйтәчәк һәм кыйраәт белгечләрен Рәсәй күләмендә тәрбияләп, үстереп чыгарырга ярдәм итәчәк.

Шунысы мөһим: Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте республикабыз өчен Коръән кыйраәтләре буенча белгечләр әзерләүдә нәтиҗәле һәм эзлекле эш алып бара. Мисал өчен, Казанның «Рәшидә» Коръән өйрәнү үзәген тәмамлап, Ливанда Әл-Җинән университетында белем алган Раушан Йосыпов 10 кыйраәт буенча белгеч дәрәҗәсенә иреште. Моннан тыш, Татарстан өчен Коръән кыйраәтләре буенча белгечләр әзерләүдә ирешелгән килешүләр нәтиҗәсендә, Төркиянең «Хасеки» югары әзерлек үзәгендә белем алучы янә бер Коръән белгече Кәлам Шәрифнең 10 кыйраәтен тулысынча үзләштереп республикабызга әйләнеп кайтачак.

Татарстан мөселманнары башлыгы Камил хәзрәт Сәмигуллин исә Коръән-Кәримне Гасыйм кыйраәтенең Шугъбә риваяте буенча укытырга мөмкинлек бирүче таныклыкка ия. Гасыйм кыйраәте – Коръәнне кычкырып уку белән бәйле булган ун кыйраәтнең берсе, ул Кәлам Шәрифне укуда ике төргә ия: аларны имам Гасыймның шәкертләре – Хафс һәм Шугъбә тапшырган. Рәсәй дин белгечләре арасында иң киң таралган Коръән уку төре булып, Гасыймнан килгән Хафс риваяте санала. Камил хәзрәт алган иҗазәт исә аның Шугъбә риваятен үзләштерүен раслый. Шул рәвешле, мөфти хәзрәт Хафс һәм Шугъбә риваятьләреннән торган Гасыйм кыйраәтенең белемнәренә тулысы белән ия.

■ **dumrt.ru сайтыннан**

# Чын мәхәббәт нидән гыйбарәт?



Аллаһы Раббыбызның кешеләргә биргән иң гүзәл нигъмәтләренең берсе – ярату хисе. Күңелендә ярату булмаган, ярата белмәгән кеше бәхетсез. Андый кеше үзен яратудан, үз ихтыяҗларын канәгатьләндерүдән ары китә алмый.

Габдулла Тукай да:

«Файдасыз бер ит кисәгеннән гыйбарәттер йөрәк –

Парә-парә кисмәсә гыйшык, мәхәббәт кайчысы», – дип язган.

Күңелендә ярату хисе булган кеше бәхетле. Ул Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешүче. Аның яратуына җавап бирәләрме, юкмы – мөһим түгел. Яратуыңа җавап көтү ул мәхәббәт түгел, ә эгоизмның бер төре. Ярату – үзеңне турында оныту, сөйгәнеңә, халкыңа, туган җиргә хезмәт итү һәм бу гамәлдән тәм табу. Менә шушы хис кешене югары күтәрә, алга барырга, авырлыкларны җиңәргә ярдәм итә.

Әлбәттә, иң бөек ярату хисе Аллаһы Тәгаләгә булырга тиеш. Әгәр кеше нәрсәнедер яки кемнедер Раббысыннан артык яратса, ул ярату аңа бәхетсезлек китерә, аны упкынга илтә, чөнки бу вакытта кеше яратканының колына әверелә, чикне югалта. Аллаһыдан курку – ул Аллаһы Тәгаләнең мәхәббәтен югалтудан курку. Иман – Аллаһыны хакыйкый ярату. Күңелендә Аллаһы Тәгаләгә мәхәббәт булган кеше Раббысы кушканнарны үтәүдән, тыйганнарыннан тыелудан тәм таба, җанына рәхәтлек ала. Бу эшләрне Аллаһы Тәгаләнең газабыннан гына куркып эшләүче каты бәгырьле була, аның гыйбадәте дә көткән нәтиҗәне бирми. Кушканнарны үтәү ул әле тәм табу түгел, ә өстән бурычны гына төшерү. Әйтик, ике кеше бер үк эшне башкара. Берсен шушы эшне эшләргә куркытып мәҗбүр иткәннәр, икенчесе үзенә эш кушучыны хөрмәт итеп, аның күңелен күрим дип, җанын биреп эшли. Нәтиҗәдә икенче кешенең башкарган эше күпкә яхшырак, күңеле дә күтәренке була, ул эшеннән рәхәтлек ала.

Кешенең калебендә иман, ярату булмаса, андый кеше корыган агачка тиң. Урманда корыган чыршылар, каеннар бар. Аларның агач икәнен дә, нинди агач икәнен дә белеп була, ләкин аларның киләчәге юк. Нәфесенә хуҗа була алмыйча үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртса, йөрәгендә иман, ярату, өмет булмаса, кешенең дә киләчәге юк. Андыйларның күзендә өмет чаткысы, нур булмый. Нинди генә матур киемнәр кисәләр дә, ул кешеләр янында үзеңне уңайсыз сизәсең. Алар турында хәзер «аурасы начар» дип сөйлиләр, элек «җан көеге» дип әйтәләр иде.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ватанны сөю иманнан», – дигән. Ватан төшенчәсенә туган җир, нигез, туган тел, әти-әни, туган-тумача да керә. Шуларга хезмәт итүдән тәм таба алмыйсың икән, син буш кеше. Иң кешелексез кеше – битараф кеше. Халкым мине аңламады, сөйгәнем мәхәббәтемә җавап бирмәде дип, бар дөньяга үпкәләп, кара көеп йөрү дөрес түгел. Кемдер синең мәхәббәтеңне җавапсыз калдырган икән, ник борчылырга, аңа карап синең ярату сәләтең кимеми. Безгә нәрсәнең хәерле икәнен Аллаһы Тәгалә генә белә. Аллаһының хәерсез эше юк, диген дә алга таба хәрәкәт ит. Җавапсыз мәхәббәт, әгәр ул чын мәхәббәт булса, нәфесне канәгатьләндерү теләге генә булмаса, сине чарасызлык упкынына төшерми, ә киресенчә, үҗәтрәк булырга, югарырак күтәрелергә ярдәм итә. Яраткан кешең каршында матур булып калырга, рәхәтлек тудырырга тырышырга кирәк. Сөйгәнең, халкың каршында түбәнлеккә төшү, кешелек сыйфатларыңны югалту берәүне дә бизәми, яраткан кешеңә, халкыңа сөенеч тә китерми. Яраткан кешеңнең шат йөзле, бәхетле булуын күрү – үзе бәхет.

Бар нәрсә дә тәкъдирдә язылган, аны үзгәртеп булмый. Әмма һәркайсыбызга яхшылыкка омтылу, матурлыкны тудырырга тырышу сәләте бирелгән. Аллаһы Тәгалә каршында безнең әнә шул тырышлыгыбыз бәяләнә. Тормыш ничек кенә сынаса да, без сыгылырга, төшенкелеккә бирелергә тиеш түгелбез. Күпме генә уфтансак та, үткәнне кире кайтарып булмый. Ә алга барырга, матур киләчәк булдыру өчен тырышырга мөмкинлекләр бар. Якты киләчәктән өмет өзү, матур киләчәк турында хыялланмау Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән өмет өзүгә тиң. Раббыбыз һәркемгә дә сайлау һәм хәрәкәт итү мөмкинлеге биргән. Кире кагылу, егылу гаеп түгел, егылгач торырга тырышмау – гаеп. Язучы, композитор гына иҗат итми, һәр һөнәр иясе иҗат итә. Бары хезмәтеңне иҗатка әйләндерергә генә кирәк. Мисал өчен, бер үк рецепт буенча, бер үк ризыктан өч кеше аш пешерә ди. Беренчесе ашыйсы килгәнгә, икенчесе пешекче булганга, өченчесе пешерергә ятратканга. Нәтиҗәдә ни күрәбез? Әлбәттә яратып пешерүченең ашы тәмлерәк була.

Кырда эшләүнең дә, терлек караунын да, кирпеч салуның да үз аһәңе, үз матурлыгы бар. Шуны күрә, тоя белергә, аннан тәм табарга һәм балаларыбызны да шул матурлыкны күрә белергә өйрәтергә кирәк. Кеше эшкә бара, кайта, акча эшли, гаиләсен туйдыра. Бай булып та яшәргә мөмкин. Ләкин хезмәтең иҗат дәрәҗәсенә күтәрелмәсә, бәхетле була алмыйсың, зарланып, кемнедер сүгеп, кәефсезләнеп гомер кичерәчәксең. Күңел ачуларга йөреп, кәеф-сафа корып, күңел бушлыгын тутырмакчы булсаң да, барып чыкмый, чөнки бу дөрес юл түгел.

Кешеләр яратып өйләнештек диләр, әмма тормышлары барып чыкмый. Ә ярату кая киткән? Ярату булмаган! Бу бары тик нәфес теләгән ярны гына үзеңнеке итү булган. Болар икесе ике әйбер. Әгәр яратасың икән, син яраткан кешеңә хезмәт итүдән, уңайлык тудырудан, аның елмаеп көлүеннән рәхәтлек алырга тиешсең. Шулвакытта гына тормыш бәхетле була. Хатын иренә, ире хатынына уңайлы булсын дип тырыша икән, менә бу – ярату. Бер-берсенә яхшы шартлар тудыру, күңел күтәрү өчен бар сәләтен, тырышлыгын куйган парлар йортын бәхет беркайчан да ташламый. Берәү дә уңайлыктан туймый, киресенчә, һәркем рәхәт тормышны югалтудан курка. Әгәр гаиләдә шушы гармония бар икән, гаилә тотрыклы була, ярату берберенңнән башка тора алмау дәрәҗәсенә күтәрелә.

Соңгы вакытта экраннарда бара торган «Нелюбимый» фильмы моның ачык мисалы. Төп героиня, язмышына буйсынып, сөйгән егетен калдырып, үзе битараф булган, әмма аны бик ярата торган егеткә кияүгә чыга. Хатыны бәхетле булсын өчен, әлеге ир көченнән килгәнен дә, булдыра алмаганын да эшли. Ә героиня исә элек сөйгән ярын яратам дип уйлый, аңа булган мәхәббәтен йөрәгендә йөртә. Һәм бары тик фильмның ахырында гына ул үзенең ялгышуын, яратмыйча гына кияүгә чыккан ирен яратуын, аннан башка тормышын күз алдына да китерә алмавын аңлый. Бу фильмда уйланырлык әйберләр күп. Әгәр син тормышыңны үзеңнең нәфесеңне канәгатьләндерү өчен генә корсаң, бернәрсә дә барып чыкмый, чөнки нәфеснең чиге юк. Коммунистик идеологиянең тормышка ашмавы да аның «һәркемгә хаҗәтенчә, һәркемнән сәләтенчә» лозунгына корылган булуында. Бу әкияттәге кызның төпсез чиләккә су тутыруына тиң. Ә хакыйкый тормышта ул «күбрәк эләктер, ераграк кач (урвать кусок побольше, удрать подальше)» дигәнгә кайтып кала. Моның ачы җимешләрен бүген дә татыйбыз. Җитәкчеләр үз мәнфәгатьләрен җәмгыять, халык мәнфәгатьләреннән өстен куйганда, ил алга бара алмый. Гаиләдә дә шулай ук. Кем дә булса үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртса, гаилә таркала. Бүген яңа корылган гаиләләрнең күпчелеге җимерелә икән, димәк без балаларыбызны кемгә дә булса хезмәт итүдән тәм табарга өйрәтмәгәнбез, эгоистлар үстергәнбез булып чыга. Бала уенчыгы белән уйнаудан гына түгел, уенчыгын башкаларга биреп торудан да тәм табарга тиеш.

Фәрһәд һәм Ширин мәхәббәтеннән күпләребез хәбәрдар. Сөйгәне, тауны ярып (кисеп), су каналы ясарга кушкач, Фәрһәд, уйлап та тормыйча, тау кисәргә тотына. Ару-талуны, авыртуны белми онытылып эшли һәм максатына ирешә.

Ә без бер-беребезгә әз генә булса да уңайлык тудырырга, йомшак сүз әйтеп күңелен юатырга үзебездә көч таба алмыйбыз. Ул аны, моны тиеш, тегене, моны эшләмәгән дип, үзебезгә аклану эзлибез. Каршы якны гаепләү – үзеңнең булдыксызлыгыңны танудан качу ул. Бу юл белән гаиләне саклап та, бәхетле итеп тә булмый. Нинди генә очракта да матур киләчәк өчен тырышырга, көч куярга кирәк. Нәтиҗәгә ирешә алмасаң да тырышлыгыңны, яхшы ниятеңне Аллаһы Тәгалә бәяли, бу дөньяда булмаса, Ахирәттә әҗерен бирә. Иманлы кешегә тагын ни кирәк?

Шулай ук каршы якның килеп гафу үтенүен көтеп утыру ярату түгел, ә эгоизм. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Берәү хаксыз булып, килешергә адым ясаса, җәннәтнең кырыенда урын алыр. Ә хаклы була торып та, бу адымны беренче эшләсә, җәннәтнең уртасында урын алыр», – дип әйткән.

■ ***Җәлил хәзрәт Фазлыевның***
**«Күңел бакчасы» китабыннан**

# Ибраһим галәйһиссәлам кыйссасы

*Дәвамы. Башы алдагы санда*



## Исмәгыйль галәйһиссәламнең тууы

Риваятьләрдә Ибраһим галәйһиссәлам үз халкын калдырып һиҗрәт кылганнан соң ялгыз кала, дип хәбәр ителә. Кардәшләреннән читтә калып ул үзен тулысы белән Аллаһыга багышлап, Аңа бөтен җаны белән бирелеп гыйбадәт кыла. Раббыбыз аңа иксез-чиксез байлыклар насыйп итә, әмма бала бәхетен генә бирми. Ибраһим галәйһиссәлам үзенә тәкъвалы нәсел дәвамчыларын сорап күп дога кыла, ир-бала туса, хәтта аны Аллаһы ризалыгы өчен корбан итәргә нәзер әйтә.

Ибраһимның бала теләве аның хатыны хәзрәти Сараны да борчый. Әмма ул үзен бала тудырырга сәләтсез һәм карт дип саный. «Бәлки, Аллаһы Тәгалә Ибраһимга икенче хатыннан бала насыйп итәр», – дип хәзрәти Сара иренә яшь хатынны – үзенең хезмәтчесен бүләк итеп тапшыра.

Аллаһы тәкъдире белән хәзрәти Һаҗәр никахның беренче төненнән үк балага уза. Бу сабый Исмәгыйль галәйһиссәлам була. Коръәндә моның хакта болай дип әйтелгән:

**«Без аны йомшак холыклы бер ир бала (булган Исмәгыйль (галәйһиссәлам) белән сөендердек».**

Саффат / Сафта торучылар, 37:101

Ибраһим галәйһиссәламнең куанычын күз алдына китерү кыен түгел. Күпме догалар кылганнан соң Аллаһы Тәгалә аңа 100 яшендә сау-сәламәт ир-бала бүләк итә.

Ләкин вакыт узу белән хәзрәти Сара Ибраһим галәйһиссәламне хәзрәти Һаҗәрдән көнли башлый. Хисләр акылны камап ала һәм ул хәзрәти Һаҗәрне үз яныннан читкә җибәрергә сорый.

## Хәзрәти Һаҗәр өчен бөек сынау

Ибраһим галәйһиссәлам Аллаһы насыйбы белән Җәбраил галәйһиссәлам артыннан хәзрәти Һаҗәрне һәм аның күкрәк сабыен алып юлга чыга. Мәккәгә җиткәч, ул аларны, Яратучыга ышандырып, хәзерге көндә Зәм-зәм чыганагы аккан урында калдырып китә. Тирә якта буп-буш һәм коп-коры чүл генә була. Һаҗәр һәм кечкенә Исмәгыйль галәйһиссәламдә бары бер кәрзин хөрмә җимеше һәм турсык белән су гына була. Ибраһим галәйһиссәламнең мондый гамәленә аптыраган һәм улы белән икесенең алдагы язмышларын күз алдына да китерергә курыккан яшь ана берсүзсез аларны ташлап киткән ире артыннан чабып китә. Ул:

– Бер җан иясе һәм бер тамчы су булмаган шушы эссе чүлдә безнең ничек калдырып китәсең? – дип әйтә.

Ибраһим галәйһисәлам исә бер сүз дәшмичә һәм борылып та карамыйча юлын дәвам итә. Хәзрәти Һаҗәр аңа артыннан бу сүзләрне берничә тапкыр кычкырып кабатлый. Шуннан соң ул болай дип сорый:

– Синә Аллаһы шулай эшләргә куштымы?

Бу сораудан соң Ибраһим галәйһиссәлам аңа борылып җавап кайтара:

– Әйе, Раббыбыз шулай кушты. Мин сезне Аңа ышандырып тапшырам.

Әлеге сүзләрне ишеткәч, хәзрәти Һаҗәр:

– Алай булгач, Ул безне ташламас. Аллаһы Тәгалә безгә җитә, – дип әйтә.

Ибраһим галәйһиссәлам Һаҗәр күрмәс ераклыкка җиткәч, яшьләренә тыгылып Аллаһыга дога кыла:

**«Ий, Раббыбыз! Һичшиксез, мин нәселемнең бер өлешен игенсез бер үзәнлеккә, (үзенә дә, янында яшәүчеләргә дә һөҗүм итү һәм мәсхәрәләү) харам кылынган йортың янында урнаштырдым. Ий, Раббыбыз! Намаз укысыннар. Кешеләрдән кайберләренең күңелләрен (Мәккәгә урнаштырган гаиләмә һәм алардан таралачак яңа буыннарга) авыштыр һәм аларны (тирә-яктагы мәмләкәтләрдә өлгергән һәм ерак җирләрдән кайтарылган төрле-төрле) җимешләрдән ризыкландыр, бәлки, алар (намазларын тиешенчә укып һәм бүтән гыйбадәтләрен җиренә җиткереп, бу нигъмәтләргә) шөкер итәрләр».**

«Ибраһим», 14:37

Ибраһим галәйһиссәлам укыган доганың бәрәкәте белән Раббыбыз кешеләрнең йөрәкләрен шушы чүл урынына карата ача. Элек бер йорт та булмаган, хәтта кәрван юллары да үтмәгән бу чүл бүген һәр мөэминнең күңелендә саклана торган, үзенә Җир шарының төрле почмакларыннан күпмиллионлаган халыкларны тартып торган Мәккә-и Мөкәррәмә шәһәре булып тора.

Әнә шулай итеп, хәзрәти Һаҗәр улы белән бергә шушы буш урынга тормыш өрә. Ул Ибраһим галәйһиссәлам калдырган турсыктан су эчеп, хөрмә җимешләрен ашап, баласын имезә. Ләкин ризык бер мәлне бетә башлый, кояш эсселегеннән качар җир дә булмый. Хәзрәти Һаҗәрнең күкрәк сөте бетә, ачтан ярсып елаучы баласына карап йөрәге әрни, ләкин берни эшли алмый.

Хәлсезләнеп калып, ул бары бер җан иясе килеп чыкмасмы дигән өмет белән як-ягына каранып утыра. Ерак түгел урнашкан Сафа тавына менеп тә күзәтеп карый. Аннан соң бертуктаусыз дога укып, баласын кочаклап үзәнлеккә төшә һәм Мәрва тавына менеп карый. Шушы Сафа һәм Мәрва таулары арасын аңа җиде тапкыр үтәргә туры килә. Һәм хәзрәти Һаҗәр могҗизага тап була.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Хаҗилар нәкъ шуңа күрә Сафа һәм Мәрва таулары арасын җиде тапкыр үтә», – дигән сүзләре билгеле.

## Зәм-зәмнең барлыкка килүе

Һаҗәр соңгы тапкыр Мәрва тавына менгәч, берничә рәт кеше тавышы ишетә. Беркемне дә күрмәгәч, болай дип сүз ката:

– Ий, тавыш иясе, син үзеңне белдердең. Әгәр дә ярдәм итә алсаң, күрен һәм булыш.

Шулвакытта Зәм-зәм барлыкка киләчәк урында Җәбраил галәйһиссәлам пәйда була. Исмәгыйль елавыннан туктый алмыйча, аяклары белән җирне дөп-дөп таптый. Җәбраил галәйһиссәлам сабый аягы белән таптаган урынга канаты белән кагылып ала, һәм бу җирдән су чыганагы бәреп чыга. Хәзрәти Һаҗәр моны күреп, куана-куана турсыкны су белән тутырам дип, «зәм-зәм» яки «тукта-тукта» дия-дия, су читкә китмәс өчен, чыганакны ком белән коймалап алырга тырыша.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Исмәгыйль анасы Һаҗәрне Аллаһы кичерсен: Зәм-зәм чыганагын тынычлыкта калдырса, ул елга булып агып китәр иде» – дип әйткәне турында хәбәр ителә.

Югыйсә хәзрәти Һаҗәргә: «Су китә дип борчылма! Аллаһы аны синең һәм улың өчен чыгарды. Ул беркайчан саекмаячак», – дип әйтелә.

Белгәнебезчә, шушы көннән алып һәм бүгенге заманга кадәр бу чыганак кешелек дөньясын үзенең шифалы суы белән куандырып тора һәм, иншә Аллаһ, Кыямәт көненә кадәр куандырып торыр. Һәр мөэминнең, хаҗда булу-булмавына карамастан, бу судан авыз иткәне булгандыр, мөгаен. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең болай дип әйткәне хәбәр ителә: «Дөньядагы иң яхшы су – Зәм-зәм. Бу су тукландыра һәм авыруларга шифа бирә».

Зәм-зәм хәзрәти Һаҗәрне һәм кечкенә Исмәгыйльне дә, бу җирлеккә кешеләр килеп урнашканчы, ризыкландырып та, сусауларын басып та торган.

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан Республикасы мөфтие**

# Гаилә әһелләренә гыйлем бирү



Барча мактаулар, хәмде-сәналәр Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгаләгә һәм Аның хак хәбибе, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребезнең түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Һәрберегез көтүче һәм һәрберегез үз көтүе өчен җавап бирә», – дип әйткән. Без – гаиләбез әһелләре өчен җавап тотачак кешеләр. Безнең өстә гаиләбезне тәэмин итү: ашатып-эчертү, киендерү генә түгел, ә ике дөнья бәхетенә ирешүдә ярдәм итү бурычы да салынган. Шуңа да гаилә әһелләребезгә гыйлем бирү, балаларыбызга динебез Исламны: Коръәнне, сөннәтне өйрәтү мөһим. Бу мәсьәләләргә җитди карасак иде.

Бала күңеле ак кәгазь кебек. Ул ак кәгазьне матур, мәгънәле бизәкләр, язулар белән баетыйк, чөнки нәкъ менә кечкенә вакытта өйрәнгәннәр хәтергә ныграк сеңеп кала. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм юкка гына, 7 яшь тулу белән үк балаларыгызны намазга бастырыгыз, дип әйтмәгән. Бу зур эшләрне кичектереп, соңрак үзебез үк үкенмәсәк иде. Шау-шулы, ыгы-зыгылы, мәшәкатьле дөньяда гаилә әһелләребезгә дини гыйлем бирүгә вакыт табыйк, хөрмәтле мөселман кардәшләребез!

Әйе, бәлки динне чит кешегә өйрәтү күпкә җиңелрәктер. Башкаларны өйрәткәндә, аларга нәсыйхәт биргәндә без дулкынланмыйбыз, аларга әйткәннәребез ошау-ошамау турында борчылмыйбыз, үз фикерләребезне иркен рәвештә әйтәбез, чөнки бу кешеләр безне шәхсән белмиләр, алар безнең белән яшәми, безне көнкүрештә күрми. Ә менә үз йортыбызда, гаиләбездә, туганнарыбыз, дусларыбыз, күршеләребез янында эшләр башкачарак. Без сүзләребезне сайлап кына кулланабыз, аларга нәсыйхәт биргәндә ялгыш кына үпкәләтүдән, артык сүз әйтүдән куркабыз. Моңа өстәп, әлеге кешеләр безне бик яхшы белгәнгә күрә, әңгәмә вакытында безнең элеккеге хаталарыбызны искә төшереп, безне уңайсыз хәлдә калдыруларын уйлыбыз. Әлбәттә, болар барысы да бездән якыннарыбызга нәсыйхәт, гыйлем биргәндә тагын да игътибарлы булуыбызны таләп итә.

Изге Коръәни Кәримебездә китерелгән хикмәтле кыйссалар безне уйланырга мәҗбүр итә. «Мәрьям» сүрәсендә Ибраһим галәйһиссәламнең потлар ясаучы әтисе белән әңгәмәсе бәян ителгән:

**«Менә ул атасына әйтте: «И, әтием! Ни өчен (ялваруларыңны) ишетмәгән, (үзләренә баш июләреңне) күрмәгән һәм сине бернәрсәдән дә коткара алмаган нәрсәләргә табынасың?»**

«Мәрьям», 19:42

Күпме хөрмәт, ярату, якын итү, борчылу салынган әлеге сүзләргә! Без якыннарыбыз белән нәкъ менә шул рәвешле аралашырга тиеш. Аларны дингә чакырганда сабыр һәм хикмәтле булу кирәк. Кул селтәп, йөзне бору бик җиңел. Ә менә максатыңа ирешү күп тырышлык, көч куюлар таләп итә. Шушы ук сүрәдә Исмәгыйль галәйһиссәлам хакында искә алына:

**«Ул халкына намазны һәм зәкятне әмер итә иде. Раббысы аңардан разый иде».**

«Мәрьям», 19:55

«Иде» сүзе кабатланып килә торган гамәлне белдерә. Димәк, ул бу нәсыйхәтләрне иртән дә, кичен дә әйтә торган булган, озак вакытлар исләренә төшереп яшәгән. Без исә бик тиз үпкәлибез, тиз арада нәтиҗәләр булуын көтәбез. Хатабыз да шунда. Әмма күз алдыбызга китереп карыйк әле: әгәр дә без куйган максатыбызга ирешсәк, нинди зур эш башкарган булабыз. Гаиләбез, якыннарыбыз белән бер юлдан бару зур бәхет бит. Моны башкарып чыккан очракта гаилә әһелләребез белән бер-беребезне бер сүздән аңлап, үзара тагын да дус-тату мөнәсәбәттә яшәячәкбез, иншә Аллаһ. Әлбәттә, бу дөньяда бер юлдан барган, бер юнәлештә хәрәкәт иткән кешеләр Аллаһының рәхмәте белән Ахирәт көнендә дә бергә булырлар дигән өмет зур. Коръәни Кәримдә болай дип әйтелгән:

**«И, иман китерүчеләр! (Әмерләрне тотып, тыюлардан тыелып) Үз-үзләрегезне һәм гаиләләрегезне уттан саклагыз, (башка утларның ягулыгы утын булса) аның ягулыгы (кяфер) кешеләр һәм (бик тиз кабынып, бик күп яндыра торган күкерт) ташлар. Аның өстендә каты табигатьле һәм көчле фәрештәләр бар. Алар үзләренә әмер ителгән нәрсәләрдә Аллаһыга каршы төшмиләр һәм әмер ителгәнне үтиләр».**

«Тәхрим / Тыю», 66:6

Шуның өчен бу мәсьәләләргә җитди карасак иде, җәмәгать.

Әлбәттә, без бу гамәлләрдә сәбәпче генә. Күңелләргә салучы, йөрәкләрне йомшартучы, хакыйкатьне танытучы – Аллаһы. Әмма без гаилә әһелләребез белән бергәлектә намазлар укырга, аларга хәдисләр өйрәтергә, белгәннәребез, укыганнарыбыз белән уртаклашырга бурычлы. Ризаэтдин Фәхретдин хәзрәтләре: «Алтыннан кыйммәтле, оҗмах нигъмәтләреннән дә кадерле булган нәрсә – тәрбияле баладыр», – дип әйткән. Шулай ук аның: «Бала чакта алынган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас», – дигән гыйбарәсе билгеле.

Аллаһы Тәгалә белгәннәребез белән гамәл кылып, гаиләбезгә, якыннарыбызга, әйләнә-тирәдәгеләребезгә үрнәк булып яшәүләребезне һәм изге ниятләребез белән динебез Исламны бары күркәм яктан күрсәтә алуларыбызны насыйп итсә иде. Үзебездән соң да догачы, ихлас, тәкъва балалар калдырып, алар да үз балаларына бездән алган тәрбияне ирештерә алсалар иде.

**«И, Раббым! Мине намаз үтәүче һәм минем нәселемне дә (намаз әһеленнән кыл). И, Раббыбыз! Догамны кабул әйлә».**

«Ибраһим», 14:40

■ **Тимергали хәзрәт Юлдашев, «Саләх» мәчете имам-хатыйбы**



# Изге гамәлләр иманга керәме?

**Сорау: Әссәләмү галәйкүм! Изге гамәлләр иманга керәме? Намаз укымаган, ураза тотмаган кеше иманлы саналамы?**

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләм! Әһле Сөннәт Вәл-Җәмәгать карашынча, иман – ул Аллаһы Тәгаләдән Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм аша китерелгәннәргә калеб белән ышану дигән сүз. Кайбер галимнәр калеб белән ышануга тел белән тәсдыйкъ итүне дә өстиләр.

Кешенең гамәлләре иманга керми. Имам Әбү Хәнифә рахимәһуллаһи «Васыя»сендә болай дип әйтә:

«Гамәл – ул иман түгел, ә иман – гамәл түгел».

Галимнәр бертавыштан «гамәл» дигәндә Аллаһы Тәгалә кушкан гыйбадәтләрне (намаз, ураза) үтәүне һәм Ул тыйган гамәлләрдән (шәраб эчү, зина кылу) ерак булуны күздә тоталар.

Элеккеге галимнәр иманга калеб белән ышануны да, тел белән раслауны да һәм Ислам баганаларында булган гамәлләрне кылуны да керткәннәр. Бу билгеләмә буенча гыйбадәт кылмаган кеше иманлы булмый дип аңлау тиешлеме? Юкса ул иманның бер өлешен төшереп калдырган була? Хариҗилар, могътәзили кебек секталар шулай уйлый да һәм намаз укымаган, ураза тотмаган кешене кяфер дип саный.

Әһле Сөннәт һәм элекке чор галимнәре гамәлләрнең камил, тулы иманның бер өлеше булуына басым ясаганнар. Иманның камиллегенә гыйбадәтләр аша ирешү белән килешәбез.

Безнең галимнәр гамәлләрнең иманның бер өлеше булмавын 3 төрле алым белән дәлилләләр:

1. Иман һәм гамәл сүзләре Коръәндә еш кына «һәм» теркәгече белән кулланыла, ә гарәп, татар һәм рус телләрендә алар икесе бер әйбер дигән сүз түгел. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Иман китерүчеләрне һәм (намаз, ураза, хаҗ, зәкят кебек Китап белән Сөннәткә муафыйк) изге гамәлләр кылучыларны, аларга (сарайлары һәм агачлары) асларыннан елгалар аккан җәннәтләр белән сөендер. (Җәннәт бакчаларыннан) Нинди дә булса җимешләр бирелгән саен алар: «Бу нәрсә безгә элек тә (дөньяда) бирелгән иде бит инде!» – диярләр. Ул (ризыклар) аларга (төсе һәм шәкеле белән генә) бер-берсенә охшаган (ләкин тәме, ләззәте белән бик нык аерыла торган) итеп бирелгән иде. Аларга анда – (хәез һәм нифас кебек матди нәҗесләрдән, бигрәк тә көнләшү, бозыклык кебек рухи кимчелекләрдән) пакь хатыннар (алар дөнья хатыннарыннан һәм хур кызларыннан булыр). Һәм алар анда мәңге калачак».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:25

2. Коръәндә иман изге гамәлләрнең кабул булуына бер шарт буларак искә алына. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

**«(Игелекләр кылып, яман эшләрдән ерак торган) Игелек иясе буларак үзен Аллаһыга тапшырган һәм (ялган диннәрне ташлап, хакыйкатькә юнәлгән) хәниф Ибраһим галәйһиссәлам диненә ияргән кешедән дә дин ягыннан яхшырак кем була ала? Аллаһы Ибраһим галәйһиссәламне Үзенең дусты итте».**

«Нисә / Хатыннар», 4:125

3. Аллаһы Тәгалә кайбер гамәлләрне кылмаучы мөселманнарны иманлы саный:

**«Әгәр мөэминнәрдән ике төркем берберләре белән сугышсалар, (нәсыйхәт биреп, булса, Аллаһының хөкеменә чакырып) аларны татулаштырыгыз. Әгәр дә берсе икенчесенә карата бозыклык кылса, ул бозыклык кылучы белән Аллаһының әмеренә (һәм хөкеменә) кайтканчы сугышыгыз. Әгәр дә (сезнең белән сугышуга бара алмыйча, Аллаһының әмеренә) кайтса, (сугышны туктату белән генә канәгатьләнмичә), гаделлек белән араларын татулаштырыгыз. (Кыласы һәм кире кагасы һәр очракта) Гадел булыгыз. Һичшиксез, Аллаһы гадел булганнарны сөя».**

«Хөҗерат / Бүлмәләр», 49:9

Димәк, гамәлләр иманга керми, әмма иманның камиллегенә тәэсир итә. Камил иман гамәлләрсез булмый.

Ә Аллаһы яхшырак Белүче!

# Аллаһының сыйфатлары



**Сорау: Әссәләмү галәйкүм! Мөселман кешесе Аллаһының нинди сыйфатларын белергә тиеш?**

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәлам! Аллаһының сыйфатлары арасыннан галимнәр Аның Бар булуын (Әл-Вөҗүд) аерым күрсәтәләр.

Аллаһының Бар булуыннан тыш, тагын ике төркем сыйфатын аерып чыгаралар Алар:

Аллаһының кимчелекләрдән пакь булуы һәм Аллаһының камиллеген раслый торган сыйфатлар.

Аллаһының кимчелекләрдән пакь булуын раслый торган сыйфатлар (аларны гарәпчә «сыйфат сәлбия» дип атыйлар) бишәү. Алар:

1) Башлангычы булмау – Әл-Кыйдәм.

2) Ахыры булмау, Мәңгелек – Әл-Бәка'ә.

3) Үзенең барлыкка китерелгәннәреннән аерылып тору – Әл-Мухаләфәтү лил-хәвадис.

4) Бердәнбер булу – Әл-Вәхдания.

5) Мөстәкыйль булу – Әл-Кыямү бинәфсиһи.

Икенче төркем сыйфатлар – Аллаһының камиллеген белдерә торган сыйфатлар (аларны гарәпчә «сыйфат сүбүтия» дип атыйлар) түбәндәгеләр:

1. Яшәеш (Әл-Хәят).
2. Гыйлем (Әл-Гыйлем).
3. Ихтыяр (Әл-Ирадә).
4. Кодрәт (Әл-Кудрат).
5. Юктан бар итү (Әт-Тәквин).
6. Сөйләм (Әл-Кәлам).
7. Ишетү (Әс-Сәмгу).
8. Күрү (Әл-Бәсар).

Болар – дәрәҗәле Әһле Сөннәт галимнәре (әшгарыйлар һәм матуридилар) үз хезмәтләрендә искә алган сыйфатлар. Бу сыйфатларга капма-каршы булган үлем, гыйлемсезлек, көчләү, хәлсезлек, берни барлыкка китерә алмау, телсезлек, ишетмәү, күрмәү кебек сыйфатлар Аллаһыга хас сыйфатлар түгел. Мөселман кешесе Аллаһының тискәре сыйфатлары булмавына, Аның бары тик камиллек сыйфатлары гына булуына инанырга тиеш. Әгәр аннан «Аллаһы белүчеме?» дип сорасалар, ул «Әйе», «Аллаһының ахыры бармы?» дип сорасалар, «Юк», дип җавап кайтарырга тиеш.

Ә Аллаһының сыйфатларын күңелебезгә салып куеп, яттан белсәк тагын да хәерлерәк.

■ **Булат хәзрәт Мөбарәков, ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе**

# Мөселман яшьләре форумында экваторны билгеләп үттеләр






19 нчы август көнне X Мөселман яшьләре форумында катнашучылар җыенның яртысын тәмамлады һәм символик экватор ноктасына килеп җитүне билгеләп үтте. Исегезгә төшерәбез, быел Мөселман яшьләре форумы үзенең форматын төптән үзгәртте. Оештыручылар катнашучыларның кызыксынуларын истә тотып 5 мәйданчык булдырды: Коръән, әдәп-әхлак, медиа, социаль проектлар һәм туризм. Һәр тематик секция кысаларында экспертлар эшли һәм яңа практик күнекмәләргә өйрәтү алып барыла. 18 яшьтән 30 яшькә кадәрге 100 катнашучының һәркайсы үзенә ошаган бер мәйданчыкны сайлап алган.

Шулай итеп, проект мәйданчыгында «Куркуны ничек җиңәргә?» темасына лекция белән «Түбәтәй» челтәренә нигез салучы Солтан Сафин чыгыш ясады. Форумда катнашучыларга социаль грантлар турында Социаль өлкә инновацияләре һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар үзәге җитәкчесе Антон Дыганов сөйләде. Ислам бизнесы этикасы белән РИУ мөгаллиме, гакыйдә, хәнәфи фикһе буенча китаплар һәм мәкаләләр авторы Әхмәд Әл-Хәнәфи таныштырды. Медиа мәйданчыгында лекцияләр белән блогерлар һәм маркетологлар чыгыш ясады. Алар катнашучыларга инстаграм алып барганда күзәтелә торган хаталар, үз хезмәтләреңне интернет аша сату тәртипләре һ.б. турында чыгыш ясады. Туристлык мәйданчыгында белгечләр катнашучыларга спорт һәм хәләл туризм турында сөйләде. Спикерлар арасында танылган туристик блогер Газизә Ракитская бар иде. Әдәп-әхлак мәйданчыгында лекцияләр белән Алабуга районы имам-мөхтәсибе Хәлим хәзрәт Шәмсетдинов, Казанның «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы, социология фәннәре кандидаты Рөстәм хәзрәт Хәйруллин һәм башкалар чыгыш ясады. Үз чыгышларында алар белем алуның файдасы, нәфес белән көрәшү ысуллары һ.б. турында сөйләде. Коръән мәйданчыгы кысаларында балалар көн саен тәҗвид, мәхраҗ һәм башкалар өстендә тырышлык куя. Аларга бу эштә Некаддам остаз һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөгаллимәсе Ландыш Ибраһимова ярдәм итә.

Моннан тыш, бүгенге көнне Мөселман яшьләре фестивале кәрәзле элемтә чараларыннан баш тартып уза. Форумда катнашучылар телефоннардан башка гына сәяхәткә чыкты.

Форум Алабугада үтте һәм 2020 елның 22 августына кадәр дәвам итте.

Мөселман яшьләре форумы яшьләргә үз-үзләрен күрсәтергә генә түгел, ә берләшергә, танышырга, рухи яктан баерга һәм үзләренең социаль башлангычларын тормышка ашырырга мөмкинлек бирә. Яшьләр форумында катнашучылар тәкъдим иткән кайбер проектлар Татарстан Республикасы мөфтияте һәм районнардагы мөхтәсибәтләр тарафыннан уңышлы рәвештә тормышка ашырыла. Мәсәлән, аларның иң популярлары булып: намаз укырга һәм ислам нигезләренә өйрәтү буенча «Ислам. Беренче адымнар» проекты, өммәт алдында торган иң мөһим мәсьәләләр буенча фикерләшү өчен «Лекторий», авыру балаларны дәвалау өчен «Ак кәгазьгә яңа тормыш» хәйрия акциясе һәм башкалар тора. Шул рәвешле Форумны Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең социаль проектлары генераторы дип атарга була.

**dumrt.ru сайтыннан**

# ИЗГЕ КИТАПЛАР

Пәйгамбәрләр безне Аллаһы Тәгалә белән тоташтыра торган күпер сыман. Һәрбер пәйгамбәр – ул Аллаһы Тәгаләнең сүзләрен ирештерүче илче. Аллаһы Тәгаләдән бирелә торган гыйлемнәр вәхи дип атала. Вәхи – Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгаләнең сүзләре. Бу бөек сүзләр тупланган китаплар Изге Китаплар дип йөртелә. Аларда Аллаһыдан пәйгамбәрләргә дөрес юлны күрсәтү максатыннан тапшырылган гыйлемнәр урын алган.

Аллаһы кайбер пәйгамбәрләргә китаплар, ә кайберләренә берничә биттән торган сәхифәләр биргән.

Бүген җир йөзендә Аллаһыдан килгәнлеге мәгълүм булган 4 Изге Китап бар. Бу – Тәүрат, Зәбур, Инҗил һәм Коръәни Кәрим. Тәүрат белән Зәбур яһүдиләргә, Инҗил насараларга, ә Коръәни Кәрим мөселман-нарга иңдерелгән. Коръәнгә хәтле булган китапларга ышанучыларны «Китап әһелләре» (әһлел-китап) дип йөртәләр.

## Тәүрат

Тәүрат Муса галәйһиссәламгә иңдерелгән һәм яһүдиләрнең изге китабы булып тора. Бу, кешелеккә билгеле булган, иң борынгы китап. Тәүрат китабының төп нөсхәсе сакланмаган. Әлеге изге китапта булган гыйлемнәр вакытлар үтү белән үзгәргән.

## Зәбур

Зәбур Давыд галәйһиссәламгә җибәрелгән китап. Ул яһүдиләрнең Тәүраттан соң килгән икенче китабы. Бүген ул, Тәүратка кертелеп, бер бүлек буларак урын алган халәттә. Әмма, беренче тапкыр китап итеп җыелу вакыты билгеле түгел. Зәбур «мәзмүр» дип аталган өлешләргә кергән. Аның эчтәлегендә әмерләр һәм тыюлар юк. Китап шигъри формада язылган нәсыйхәтләрдән тора.

## Инҗил

Инҗил Гайсә галәйһиссәламгә иңдерелгән һәм насараларның изге китабы булып санала. Ул Гайсә галәйһиссәлам һәм аның шәкертләре үлгәннән соң язылган. Соңрак күпчелек дин белгечләре аны үзләренчә яза һәм ул бер китап булып җыела алмый. Һәрберсе үз Инҗилләрен дөрес дип саный, аңа ышана. Бу хәл бөтен тарих барышында насаралар арасында фетнә чыгуга, хәтта канкойгыч сугышлар күзәтелүгә сәбәпче була. Насара руханилары бу вәзгыятьне җайлар һәм китапларның бердәмлеген саклар өчен, Гайсә галәйһиссәламнең үлеменнән соң 325 ел үткәч, зур җыелыш оештыра. Озак вакытка сузылган фикер алышулардан соң, насара руханилары китаплар санын дүрткә калдыра. Бүгенге көндә Инҗил әлеге дүрт китапның җыентыгы булып тора.

## Коръәни Кәрим

Коръәни Кәрим Аллаһы Тәгалә тарафыннан кешеләрне туры юлга күндерер һәм нәсыйхәтләр бирер өчен иңдерелгән соңгы Китап. Аннан соң башка Изге Китаплар булмаячак. Коръәни Кәримнең кагыйдәләре Кыямәт көненә хәтле дәвам итәчәк.

Коръәннең башка китаплардан аермасы – ул Пәйгамбәребез исән вакытта ук язылган. Шулай ук пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аятьләрнең ятлануын таләп иткән. Бу тарихи гадәт безнең көннәргә хәтле дәвам итә һәм һәрвакытта да сакланачак. Коръән Пәйгамбәребезнең үлеменнән соң мөселманнарның кулында иде, ә Тәүрат Муса галәйһиссәламнең үлеменнән соң 700 ел узгач, Инҗил Гайсә галәйһиссәламнең үлеменнән соң 100-150 ел үткәч кенә китап булארак тупланган.


Коръән аерым бер халыкка гына түгел, ә барлык кешелеккә мөрәҗәгать итә. Аллаһы Тәгалә Коръәнне Кыямәт көненә хәтле сакларга вәгъдә биргән. Шуның өчен берәүнең дә Китапның хәтта бер хәрефен дә үзгәртү көченнән килмәячәк, чөнки ул Аллаһының саклавы астында.

Кеше читкә тайпылмыйча, Коръән күрсәткән юл белән барган очракта Аллаһының рәхмәтеннән мәхрүм калмаячак. Раббыбыз безне ярата. Ул Галәмнәрне һәм кешене Үзенең яратуы белән бар кылды һәм безнең йөрәкләргә дә ярату хисен урнаштырды. Җирләрнең, күкләрнең, без белгән һәм белмәгәннәрнең Раббысы булган Аллаһы Тәгаләнең яратуына лаек булуның нинди зур бәхет икәнен күз алдыбызга китерә алабызмы икән?! Моннан да зуррак нигъмәт була аламы?! Әйе, без Аллаһының яратуы белән барлыкка китерелдек һәм шул ярату белән яшибез, дуслар!

**Сәхифәне Айсылу Юлдашева әзерләде**



# Сәҗдә төрләре



## Сәһү сәҗдәсе

Сәһү сәҗдәсе – намаздагы җитешсезлекне төзәтү өчен кылына торган сәҗдә. Намазның фарыз өлешләренең берәрсе кичектерелсә яисә вәҗибләренең берәрсе төшереп калдырылса яки кичектерелсә, сәһү сәҗдәсе башкарыла. Мәсәлән, витр намазында Кунут догасын укырга онытылса; әгәр «Фатиха» сүрәсеннән соң өстәмә сүрәне укырга онытып, рөкүгъка кителсә, бу хаталарны төзәтер өчен, сәһү сәҗдәсен кылырга кирәк һәм бу вәҗиб гамәл булып тора.

Фарызларның берсен генә дә булса белә торып яисә оныткан лык белән төшереп калдыру намазны бөтенләй боза һәм сәһү сәҗдәсе кылып аны төзәтеп булмый. Мондый очракта намазны яңадан укырга кирәк. Намазның вәҗиб өлеше белә торып төшереп калдырылса, сәһү сәҗдәсе кылып моны да төзәтеп булмый. Бу очракта намазны шулай ук яңадан кылырга кирәк. Намазда берничә хата җибәрелсә, бер сәһү сәҗдәсе кылу җитә.

Намаз беткәннән соң сәһү сәҗдәсен кылырга онытып сәлам бирелсә һәм урыннан торып китсә, бу намазны яңадан укырга кирәкми.

Сәһү сәҗдәсе кайчан һәм ничек кылына?

Намазның бер фарыз яки вәҗиб өлешен кичектергән, яисә оныткан лык белән вәҗибне үтәмәгән кеше түбәндәге рәвештә сәһү сәҗдәсен башкара: әгәр ул ялгыз укучы булса, соңгы утырышта «Әттәхиятне» укыганнан соң, «Салават» һәм «Раббәнә»не укымыйча, ике якка сәлам биреп, ике тапкыр сәҗдә кыла. Һәр сәҗдәдә өчәр тапкыр «Сүбехәәнә Раббиәл-әгъләә» дип әйтә, аннан соң «Аллаһү әкбәр» дип торып утыра һәм «Әт-тәхият», «Салават», «Раббәнә» догасын укый, соңыннан ике якка да сәлам биреп, намазын тәмамлый.

Җәмәгать белән намаз кылганда имам ялгышса, оеп укучылар торып китмәсеннәр өчен, ул бары тик уң якка сәлам бирә, аннан соң сәһү сәҗдәсе кыла һәм ялгызы намаз кылган кеше шикелле намазны тәмамлый.

## Тиләвәт сәҗдәсе

Коръәннең кайбер аятьләре укылганнан соң, «тиләвәт сәҗдәсе» дип аталган сәҗдәне кылырга кирәк. Мондый аятьләр Коръәндә 14 урында очрый. Бу таләп аятьләрне ишеткән кешегә дә, аларны укыган кешегә дә кагыла. Тиләвәт сәҗдәсе – Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылуның бер төре.

Намаз кылу фарыз булган һәркемгә тиләвәт сәҗдәсен кылу да фарыз. Хатыннар хәез вакытында һәм бала тапканнан соң чистарыну чорында тиләвәт сәҗдәсен кылмыйлар.

Намазда тиләвәт сәҗдәсен башкару кагыйдәләре:

1. Намаз укыганда сәҗдә аятеннән соң Коръән укуны дәвам итү теләге булса (өч аятьтән күбрәк), бу аять артыннан ук бер тапкыр тиләвәт сәҗдәсе кылына. Шуннан соң намаз кылучылар кыямга кире кайталар һәм Коръән укуны дәвам итәләр.

2. Мондый аять соңгы аять булса яки аннан соң өч яки аннан кимрәк аять укылса, бу очракта тиләвәт сәҗдәсе кылмыйлар, намазны гадәттәгечә дәвам итәләр.

3. Намазда укылган сәҗдә аятен бу вакытта намаз укымаган берәрсе ишетсә, ул да тиләвәт сәҗдәсе кылырга тиеш була. Кемдер намаз кылганда берәүнең намаздан тыш сәҗдә аятен укыганын ишетсә, тиләвәт сәҗдәсен намаздан соң кыла.

4. Намазда сәҗдә аятьләрен укыган кеше тиләвәт сәҗдәсен намазда вакытта ук кыла, ә намаз беткәннән соң кылмый.

5. Имам намазда сәҗдә аятьләрен укыса, ул үзе дә, аның артында намаз укучылар да тиләвәт сәҗдәсен кылалар.

Намаздан тыш вакытта тиләвәт сәҗдәсен кылу кагыйдәләре:

1. Тиләвәт сәҗдәсе тәһарәтле килеш башкарыла.

2. Гаурәтең ябылган хәлдә кыйблага карап басарга һәм тиләвәт сәҗдәсе кыларга дип ният итәргә.

3. Кулларны күтәрмичә «Аллаһү әкбәр» дип әйтергә һәм сәҗдә кылырга. Сәҗдәдә чакта 3 тапкыр «Сүбехәәнә Раббиәл-әгъләә» диелә.

4. «Аллаһү әкбәр» сүзләрен әйтеп торып басарга. Шул сүзләрне әйтү мөстәхәб (саваплы) була:

غُفْرَانَكَ رَبَّنَا وَإِلَيْكَ الْمَصِرِ

«Гуфранәкә Раббәнә вә иләйкәлмәсыйр»

«Раббыбыз, Синең гафу итүеңне үтенәбез. Һәм кайтуыбыз Синең хозурыңа булачак».

6. Тиләвәт сәҗдәсе бер кат кына һәм сәламсез башкарыла.

Коръәндәге сәҗдә аятьләре:

1. «Әгъраф / Пәрдә», 7:206.
2. «Рәгыд / Күк күкрәү», 13:15.
3. «Нәхел / Умарта кортлары», 16:48.
4. «Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:107.
5. «Мәрьям», 19:58.
6. «Хаҗ», 22:18.
7. «Фуркан / Аеручы», 25:60.
8. «Нәмел / Кырмыска», 27:25.
9. «Сәҗдә», 32:15.
10. «Сад», 38:24.
11. «Фүссиләт / Аңлатылды», 41:37.
12. «Нәҗем / Йолдыз», 53:63.
13. «Иншикак / Ярылмак», 84:21.
14. «Галәк», 96:19.

## Шөкер сәҗдәсе

Төрле бәла-казалардан котылганнан соң, яки кеше тормышында берәр төрле шатлыклы вакыйга булса, ул кеше шөкер сәҗдәсен кылырга мөмкин. Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтеңне белдергән мондый сәҗдә нәкъ тә тиләвәт сәҗдәсе кебек башкарыла. Әбү Бәкер радыяллаһу ганһенең хәбәр итүенчә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм яхшы хәбәрләр алган чагында шөкер сәҗдәсе кыла торган булган (Имам Ибне Мәҗе, «Камәт», 192). Шөкер сәҗдәсе – мөстәхәб, әмма аны намаздан соң ук башкару мәкруһ була, чөнки белеме җитәрлек булмаган кешеләр бу сәҗдәне намазның бер өлеше дип уйларга мөмкиннәр. Әлеге сәҗдәне мәкруһ вакытлардан тыш теләсә кайсы вакытта кылырга була.

■ dumrt.ru сайтыннан

# Татарларның Таллиндагы янгын сүндерү депосын мәчет итүләре

Алдагы саннарда без төньяк Балтыйк илләренә ислам диненең үтеп керү тарихы һәм XIX гасырда татарларның Эстониядәге тормышы турында язган идек. Әлеге мәкаләне дәвам итеп, Эстониядә татарларның XX гасырның беренче яртысындагы тормышы турында бәян итик.

1860 елда татар сәүдәгәрләре, нигездә, Эстониянең өч шәһәрендә төпләнгән. Алар: Нарве, Таллин һәм Раквере шәһәрләре. Өстәвенә, иң алга киткәннәре булып, Нарведагы татар җәмәгатьчелеге санала. Бу шәһәрләрдә татарларның даими яшәүләренең бер күрсәткече – аларда мөселман зиратларының булуы.

1897 елда Беренче Халык санын алу мәгълүматларына караганда Таллинда 109 татар кешесе яшәгән. Әмма хәрби хезмәттә булучылар әле исәпкә кертелмәгән. Шуңа күрә чынлыкта татар-мөселманнарының саны күбрәк булган. Кайбер фикерләргә караганда, 1914 елда Таллинда чама белән 2000 татар яшәгән.

XIX һәм XX гасыр чикләрендә татар җәмәгатьчелегенең саны шулхәтле арткан ки, хәтта дини бәйрәмнәр вакытында зур биналар арендалау ихтыяҗы туган. Мәсәлән, Эстония татар җәмәгатьчелеге җитәкчеләренең берсе булган Надира Айзатуллина (1928-2007) хәтирәләреннән, XX гасыр башында, бәйрәм намазын үткәрер өчен, Таллин татарларының янгын сүндерү депосын арендалаганы билгеле. Бу бина шәһәрнең үзәгендә урнашкан Виру мәйданында була.

Депо бинасы бүгенге көнгә хәтле сакланып калган. Әгәр дә бинаның архитектурасына игътибар итсәк, ул ачыктан-ачык мәчет бинасын хәтерләтә, чөнки манарага охшаган каланчасы бар. Шуңа күрә татарларның әлеге бинаны арендалавы юкка гына түгел.

Эстониядә төпләнүче татарлар үзләренең туган яклары булган Идел буе белән элемтәдә булырга һәм якташларына ярдәм итеп торырга тырышалар. Мәсәлән, сәүдәгәр Закир Закиров (Zakir Zakerov) Эстониядә XIX гасыр азагында төпләнә. Аның Таллин үзәгендәге Виру мәйданында шәхси кибете була. Закиров янында һәрвакытта да, укучылары буларак, Түбән Новгород губерниясеннән булган алты-җиде, ә кайвакытларда уникеләп якташы була. Биредә алар сәүдә кәсебенә һәм рус теленә өйрәнә. Укыту, гадәттә, ике елга сузыла. Бер ай дәвам иткән яллар вакытында укучылар туган авылларына кайтып килергә өлгерә.

1917 елгы революциягә кадәр Эстония татарлары арасында иң хөрмәтле һәм бай кеше булып Сибгатулла Мәһдиев (Sigbatulla Magdejev) санала. Җирле халык аны «татар короле» дип атый. Сибгатулла Мәһдиев Таллинга 1885 елда килеп, тиз арада бай һәм уңышка ирешкән сәүдәгәргә әйләнә. Аның байлыгы тире, келәм һәм зәркән (ювелир) эшләнмәләре белән бәйле була. Ул Санкт-Петербург, Псков белән эшлекле элемтәләрдә тора. Заказ бирүчеләре арасында хәтта зур кенәзләрнең дә булуы билгеле.

Мәһдиев Таллин шәһәр зираты янәшәсендә җир участогы сатып алып, анда аерым мөселман зираты булдыра. Зират таш дивар белән әйләндереп алына, ә тимер капкалары ислам символы булган ярымай белән бизәлә. Бөек Ватан сугышы вакытында зират бомбалар астында кала. Кызганычка, 1950 еллар башында зират тулысынча юкка чыгарыла. Шуңа да карамастан, зиратның иске диварлары сакланып калган.

Беренче Бөтендөнья сугышы, патша хакимиятенең бәреп төшерелүе һәм гражданнар сугышының ыгы-зыгылары аркасында Таллин татар җәмәгатьчелегенең кешеләре саны кими. 1918 елның 24 нче февралендә Рәсәй империясенең таркалуыннан соң, Эстония үзенең бәйсезлеген игълан итә. 1928 елда Нарведа рәсми рәвештә беренче ислам җәмәгатьчелеге оеша.

Татарлар Нарведа зур агач йорт сатып алып, аннан мәчет ясыйлар. Нарве җәмәгатьчелеге актив рәвештә татар милли үзаңын саклап калырга тырыша. Ислам җәмәгатьчелегенең икенчесе 1939 елда Таллинда теркәлә. Ислам җәмәгатьчелегенең барысының да эшчәнлеге тыела. 1944 елда, сугыш вакытында ике җәмәгатьчелекнең дә биналары җимерелә. Совет чорында ислам җәмәгатьчелеге рәсми булмаган рәвештә үз эшчәнлеген алып бара: намазлар укыла, дини йолалар үткәрелә, дини бәйрәмнәр билгеләп үтелә.

■ **Мөхсин Нурулла язмасы, islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә**

*Эстония татарларының тарихы*



*Элеккеге янгын сүндерү депосы. Хәзерге заман фотосы*



# «Ярамый»дан башларга ярамый!

Кешенең Аллаһы кушканнарны үтәп, шәригатьчә яшәргә омтылыш ясавы зур адым булып тора. Хакыйкатьне табу, күңел тынычлыгын булдыру бик тә күркәм гамәл. Әмма нәкъ менә шул вакытта кеше янында аңа ярдәм итә, аны аңлый, дөрес һәм кирәкле киңәшне бирүченең булуы мөһим. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең күңелләргә тынычлык бирә торган мәшһүр хәдисе бар. Ул: «Җиңеләйтегез, әмма авырайтмагыз, сөендерегез, әмма нәфрәтләндермәгез, читләштермәгез», – дип әйткән.

Әгәр бу сүзләрнең һәрберсен сөекле Пәйгамбәребезнең әмере итеп кабул итсәк һәм алар буенча эш кылсак, динне күркәм яктан күрсәтүдә, әйләнә-тирәдәгеләргә ирештерүдә үз өлешебезне кертүчеләрдән булыр идек. Чыннан да, хәдиснең капма-каршысы булган «авырайту, борчуга салу, нәфрәтләндерү, читләштерү» сүзләре күпләрнең дин турындагы күзаллавын үзгәртә, Аллаһыга каршы җаваплы адым ясауларын тоткарлый.

Шактый еллар элек иманга килгән, шәригатьчә яшәүне көнкүрешкә кертеп җибәргән кеше бу гамәлләргә иялəшеп кенә килүче кардәшенең хәленә керә белсен иде.

Расүлебез бер хәдисендә: «Җирдәгеләргә мәрхәмәтле булганнарга Аллаһы Тәгалә дә мәрхәмәтле», – дип әйткән. Чыннан да, мәрхәмәтле, олы җанлы була белү кешене бизи, бөекли торган сыйфат. Кызганычка, күпләр аңа ия түгел, ә булдырыр өчен тырышлык, үзеңнең Аллаһының бер колы гына булуыңны аңлау кирәк. Үзеңне күп нәрсәләргә ирешкән, Аллаһыга якынайган дип санап, бүтәннәргә өстән аска карау, аларны тәнкыйтьләргә ашыгу мөселман кешесенә килешә торган гамәл түгел. Кешене дингә чакыру, аның гүзәллеген күрсәтү өчен бигрәк тә беренче вакытта аңа карата бик игътибарлы булу кирәк. Минем намазга басасым килә, әмма алдан берсен генә укый башласам ярармы икән, дигән кешегә: «Юк, бишесен дә укы, алайса берсен генә укырга ярамый», – дип кырт кисү – хата. Бу очракта мөселман кешесе: «Әгәр синә өйрәнер өчен әлегә берсен генә уку җайлы икән – шулай укы, алга таба бишесенә дә өйрәнерсең, ә мин сиңа ярдәм итәрмен», – дип әйтергә тиеш. Намаз укымаган кешенең Рамазан уразаларын тота башларга теләве белән дә шул ук хәл. Кызганычка, кайбер кеше беренче адымнарын ясарга теләүченең: «Син намаз укымаган көе ураза тота алмыйсың», – дип күңелен төшерә. Ә намаз да, ураза да аерым гыйбадәтләр һәм аларның әҗер-саваплары да аерым бирелә.

Динне өйрәтүче хикмәтле булырга тиеш. Һәм дин юлына басарга ярдәм ит дип килгән кешегә «ярамый» дип кырт кисеп, күңелен төшерергә түгел, ә динебезнең күркәм якларын, Аллаһыга якын булып, ике дөнья бәхетенә ирешүебезне төшендерсә иде.

■ **Айсылу Юлдашева**

# Ямьсез хур кызы

Шәех Әбү Бәкер Әд-Дарир рахимәһуллаһи болай дип сөйли: «Минем кварталда үзен гыйбадәткә багышлаган бер яшь егет яши иде. Ул көндезләрен ураза тотты, төннәрен намаз укыды. Берьюлы ул миңа кереп болай дип әйтте: «Ий укытучым! Бу төнне мин йоклап киттем һәм гыйбадәт кылмыйча калдым. Шул төндә төш күрдем. Төшемдә михраб ачылды да, аннан хур кызлары чыга башлады. Элек мин аннан да матуррак берни дә күрмәдем, әмма араларыннан берсе матур түгел иде. Мин алардан:

– Бу чибәрләр һәм бу матур булмаганы кемнеке?» – дип сорадым.

Алар:

– Без – матурлар – синең үткән төннәрең, ә ямьсезе – синең бүгенге төнең. Бу төндә син йоклап киттең дә, гыйбадәтеңне калдырдың. Әгәр син бу төндә үлгән булсаң, бу матур булмаган хур кызы синең өлешеңә тияр иде, – дип әйттеләр».

**Нәсыйхәт:**

Бу бөтен төннәрен гыйбадәттә үткәреп, бары бер төнен генә калдырган кешенең хәле, ә төнлә уяу булу турында әйтеп тә тормыйча, хәтта иртәнге намазга уянмаган кешенең хәле ничек булыр?

Кеше нәфел намазларында даимилек күрсәтергә тиеш. Бер башлагач, калдырмыйча башкаруы мөһим.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы каршында, әз булса да, даими кылынган гамәл хәерле», – дип әйткән.

■ **«Рухуль Бәйан» китабыннан**

# Юмарт гөнаһлының саран мөэминнән өстенлеге



Берьюлы Яхъя галәйһиссәлам шәйтанны үз кыяфәтендә күреп, аннан:

– Әйт әле: син кемне катырак яратасың һәм кемне сөймисең? – дип сораган.

Шәйтан:

– Барыннан да бигрәк мин, мөэмин булсалар да, саран кешеләрне яратам һәм, гөнаһлы булсалар да, юмарт кешеләрне сөймим, – дип әйткән.

Пәйгамбәр галәйһиссәлам:

– Ничек итеп син мөэмин кешене ярата һәм гөнаһлыны сөйми аласың? – дип әйткән.

Ул:

– Миңа мөэминнең саранлыгы җитә. Ә юмарт гөнаһлыларны мин юмартлыклары өчен Аллаһы Тәгалә аларны туры юлга чыгарырга мөмкин булганга күрә сөймим, – дип әйткән.

Бу сүзләрдән соң шәйтан борылып китеп бара. Һәм:

– Әгәр син Яхъя булмасаң, мин сиңа боларны сөйләмәс идем, – ди.

**Нәсыйхәт:**

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Юмартлык – ул җәннәттәге агач. Әгәр кеше юмарт икән, ул бу агачның бер ботагына ябышкан кебек. Һәм бу ботак ул җәннәткә кергәнче аны калдырмаячак. Саранлык – ул җәһәннәмдәге агач. Әгәр кеше саран икән, ул бу агачның бер ботагына тотынган дигәнне аңлата. Һәм бу ботак, ул җәһәннәмгә кермичә, аны калдырмаячак».

■ **«Рухуль Бәйан» китабыннан**

# Юмартлыкның иң югары дәрәҗәсе

Гомәр радыяллаһу ганһе болай дип сөйли: «Берьюлы Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә садака таратырга кушты. Ул көнне минем байлыгым күп иде. Үз-үземә: «Бүген мин садака мәсьәләсендә Әбү Бәкерне узам», – дип әйтеп, милкемнең яртысын садака итеп бирдем.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм миннән:

– Йә Гомәр! Син гаиләңә нәрсә калдырдың? – дип сорады.

Мин:

– Йә Аллаһының Расүле! Мин аларга милкемнең яртысын калдырдым, – дип җавап бирдем.

Күпмедер вакыт үткәннән соң Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе килеп, үзенең милкен садака итте.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аннан:

– Йә Әбү Бәкер! Син гаиләңә нәрсә калдырдың? – дип сорады.

Әбү Бәкер:

– Мин гаиләмә Аллаһыны һәм Аның пәйгамбәрен калдырдым, – дип әйтте.

Шуннан соң мин үземә, бүген дә Әбү Бәкерне уза алмадым һәм беркайчан да уза алмаячакмын, дидем».

Бу очрак хакында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

– Сезнең арагыздагы аерма – сүзләрегез арасындагы аерма кебек, – дип әйткән.

■ **«Рухуль Бәйан» китабыннан**

# Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһе




**Үз исеме – Әбү Габдулла Әз-Зөбәер бине Гәввам бине Хөвәйлид бине Әсәд бине Габделгоззә бине Кусай Әл-Корайши.**

## Тууы

Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһе 594 елда Мәккә шәһәрендә дөньяга килгән.

## Исеме, нәселе

Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһенең нәсел чылбыры Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәселе белән тоташкан. Әтисе – Гәввам бине Хөвәйлид Корәеш кабиләсеннән, Хәдичә бине Хөвәйлид белән бертуган. Әнисе – Сафия бинте Габделмотталиб Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әтисе белән бертуган була.

Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһе җәннәт белән шатландырылган ун сәхабәнең берсе, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янындагы алты киңәшчесенең арасында булган.

## Сыйфатлары

Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһе озын буйлы, кыска сакаллы, зәңгәр күзле кеше булган. Пакь күңелле, ачык йөзле, эшлеклелеге, мәрхәмәтлелеге белән аерылып торган.

Аның ярдәмчел булуыннан бөтен Мәдинә халкы, бигрәк тә фәкыйрьләр һәм ятимнәр канәгать булган. Хәзрәти Зөбәер бине Гәввам: «Минем янәшәдәгеләр хаерчелектән интеккәндә, минем муллыкта яшәвемнән нинди мәгънә?» – дип бик еш кабатлаган. Шуңа да аның бөтен уйлары һәм гамәлләре башкаларга ярдәм итүдән гыйбарәт булган.

## Һиҗрәт кылуы

Беренче мөселманнар кебек үк, Зөбәер бине Гәввамга да авыр сынаулар аша үтәргә туры килгән. Алар кебек ул да диненә тугры булып, бу сынауларга нык торган. Иң элек Хәбәшигә (Эфиопия), соңыннан Мәдинәгә һиҗрәт кылган. Үзен һәм динен саклауда аңа күп көч һәм корал да кулланырга туры килгән. Бервакыт Зөбәер бине Гәввам Мәккәдә үз өендә булганда, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм кяферләр кулыннан киткән дип ишеткәч, күлмәген дә кимичә, кулына кылычын алып урамга йөгереп чыккан. Юлында ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне очраткан. Аллаһының Расүленә булган вакыйгаларны сөйләгән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аннан нәрсә эшләргә карар кылуын сораган. Зөбәер бине Гәввам: «Йә Аллаһының Расүле! Мин үзем үлгәнчегә кадәр барлык дошманнарны да юк итәр идем», – дип җавап кайтарган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аның бу җавабыннан бик канәгать калган һәм дога кылган.

## Ислам динен кабул итүе

Зөбәер бине Гәввам 16 яшендә, Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе аша Ислам динен кабул итә. Моның өчен Мәккә мөшрикләре аны кыерсыталар. Ләкин шуңа да карамастан, яшьли көчле булып, дөреслеккә омтылуы белән ул үзен һәм Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне якларга тырышкан.

Һиҗрәт кылганнан соң да, Зөбәер бине Гәввам Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм яныннан китмәгән. Бәдер, Өхед, Хөдәйбия сугышларында җаны-тәне белән көрәшкән. Үзенең кылычы белән бик оста куллана торган булган. Тирәяктагылар нинди яхшы кылыч дип гаҗәпләнә торган булганнар. Зөбәер бине Гәввам үзе исә: «Хикмәт кылычта түгел, батыр йөрәктә», – дип әйтә торган булган. Хәзрәти Зөбәернең кылычы чыннан да бик зиннәтле булган. Ул кыйммәтле ташлар белән бизәлгән һәм аның хакы өч мең дирһәм торган.

Зөбәер бине Гәввам Хандакъ сугышында Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең кушуы буенча дошман ягына барып, алар турында мәгълүмат туплап кайткан. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Һәрбер пәйгамбәрнең ышанычлы дусты һәм ярдәмчесе була. Миндә андый кеше – Зөбәер», – дип әйткән.

Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһе Ислам өчен Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм вафат булгач та, Әбү Бәкер һәм Гомәр радыяллаһу ганһүмәләр хәлифәлек кылган вакытта да ярдәм иткән.

## Юмартлыгы

Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһе бөтен малларын ятимнәр һәм мохтаҗлар өчен сарыф кыла торган булган. Ышанычлы кеше икәнен белеп, Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһегә сәхабәләр үз малларын әманәт итеп саклауга тапшырганнар.

Зөбәер бине Гәввам үзе исә: «Мин сезнең малыгызны әманәт итеп ала алмыйм, чөнки аның бозылуыннан куркам, шуның өчен малыгызны мин сездән бурычка алган кебек калдырыгыз, соңыннан алырсыз», – дип әйтә торган булган. Бигрәк тә Госман бине Гаффан, Габдрахман бине Гауф, Габдулла бине Мәсгуд радыяллаһу ганһүмнәр кебек олуг сәхабәләр аңа ышанычларын белдергәннәр.

## Байлыгы

Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһе байлыгы белән дә аерылып торган. Сәхабәләр арасында аның маллары, йортлары, кол хезмәтчеләре, чәчүлек кырлары белән берсе дә тиңләшерлек булмаган.

Сәүдә эшләрен дә хәзрәти Зөбәер бине Гәввам бик оста башкарган, төрле илләрдә сәүдәгәрлек иткән. Мәдинәдә – 11, Басрада – 2, Куфа һәм Мисырда берәр йортлары булган.

Хәзрәти Зөбәернең мал җыю максаты – аларны соңыннан мохтаҗларга, Аллаһы юлында тарату булган. Аның үзеннән: «Син бу байлыкны ничек җыя алдың?» – дип сорый торган булганнар. Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһе: «Мин беркайчан да беркемне алдамадым. Ялган юл белән сәүдә кылмадым. Сыйфатсыз товар белән эш итмәдем, бозылган әйберне сатмадым. Аз керем булуын белеп тә, күбрәк сатарга тырыша идем. Шуның белән малларымны арттырдым», – дип җавап кайтарган.

Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһе Ислам дине һәм мөселманнар өчен дә күп изгелекләр башкарырга тырышкан. Берьюлы ул 600 мең дирһәм садака бирсә, икенче вакытта 180 мең дирһәм тапшырган.

Бер риваятьтә китерелә: Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһенең мең колы булган. Алар хуҗасына ел саен бик зур табыш китергәннәр. Әмма хәзрәти Зөбәер шул табыштан бер дирһәмне дә үзенә тотмаган, барлык табышны да мохтаҗларга тараткан. Үзе үлгәннән соң да мирас малының 1/3 өлешен мөселманнарга һәм мөселман оешмаларына васыять итеп калдырган.


## Вафаты

Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһе 656 елда (36 нчы һиҗри елда), 63 яшендә Гамре бине Җәрмүз тарафыннан үтерелә. Ул дүртенче хәлифә булган Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһегә каршы чыгудан баш тарткан һәм Могавия бине Әби Суфиян гаскәрен ташлап киткән. Басрадан Мәдинәгә кайтыр юлда Гамре бине Җәрмүз аны куып тоткан һәм кылычы белән җәзалаган.

Зөбәер бине Гәввам радыяллаһу ганһегә Гали кәррамәллаһу вәҗһәһу җеназа намазы укыган. Хәзрәти Зөбәер бине Гәввам Басра янында дәфен кылынган.

■ *Сәхифәне Лилия Хәләфетдинова әзерләде*

# Ә СИН ЫШАНАСЫҢМЫ?



## (Әкият, әмма бик зур гыйбрәт)

Бер бака елга суы астыннан калкып чыгып, ярдан ерак булмаган зур таш өстенә менә дә, хәрәкәтсез калып, тирән уйга чума. «Нишләтергә инде шушы үҗәт балыкларны? «Сез яшәгән әлеге су асты дөньясыннан башка елгабыз өстендә тагын бер дөнья – җир өстендәге тормыш та бар... Андагы яктылык! Андагы матурлык! Ул искиткеч киң, гаҗәеп манзара!» – дип ничек кенә сокланып аңлатып карамадым, юк – ышанмыйлар әйткән сүземә! Сафсата имеш! И-и, мәхлуклар... Инде тагын ничек аңлатыйм? Шул хакта сүз кузгатуга, шундук тарткалаша башлыйлар, «әйдә, бар, үз юлыңда бул, без үзебез беләбез ничек яшәргә!» – дия-дия, күзләрен акайтып, ачуларын белдерергә тотыналар. Шулай да, колак салганнары да юк түгел анысы, ләкин күпчелеге ышанмый бит әйткән сүземә, һич ышанмый...

Бака шулай үзалдына уйланып яткан арада яр буена бер Кеше килә дә, әйберләрен урнаштырганнан соң, кармак җебенә җим эләктереп, шуны суга ыргыта. Күп вакыт та үтми – ялтырап торган зур балык биек чиләк төбенә олактырыла. Шушы күренештән йөрәге кысылып куйган бака «аһ!» дип әйтергә өлгерми, җимле җеп икенче тапкыр суга төшерелә һәм ымсындыргыч «күчтәнәчкә» алданган чираттагы балык та иптәше янына чиләк төбенә атыла. Шулай итеп, Кешенең зур, тирән савыты шактый тиз арада матур, таза балыклар белән тула.

Эше тәмам булгач, балыкчы кирәк-яракларын җыеп ала да кузгалып китә. Бака исә, кызыксынуын тыя алмыйча, әле бая гына елга төбендә тыныч, ваемсыз гомер кичергән, ә хәзер инде тимер чиләк эчендә дыңгычлап тутырылган иптәш балыкларны кая алып китүләрен белергә теләп, сикергәли-сикергәли, гаять куркыныч тоелган Кеше артыннан иярә.

Үз йортына кайтып җиткәч, Кеше, бакчасының аулак бер урынында махсус тимер таякчыклар көйләп, шулар өстенә зур түгәрәк таба урнаштыра да нәкъ шуның астында учак кабызып җибәрә, бака исә, агачлар артында посып, аның нәрсә эшләгәнен карап тора. Учак ярыйсы кызу янып киткәч, Кеше, балыкларны чиләктән берәм-берәм чыгарып, табага тезә башлый. Әллә чыш-пыш килгән май тавышыннан, әллә күркәм балык кавемдәшләренең әле күптән түгел генә ялтырап торган матур гәүдәләре, коточкыч кызу табада кыздырганда, шәлперәеп, төсен кискен үзгәртүдән, бака кинәт хәлсезләнеп китә, соңыннан исә, күз алдындагы караңгылык бераз таралганнан соң һушына килгәч, ул шушы куркыныч урыннан тизрәк китү ягын карый.

Яшәгән елгасына көч-хәл белән кайтып җиткәч, бака җәһәт кенә су астына чума һәм бөтен әйләнә-тирәгә сөрән салып, балыкларга үз күзләре белән күргән тетрәндергеч хәлне кабалана-кабалана сөйләргә тотына:

– Җәмәгать!!! Шушы елганы һәм монда булган бөтен нәрсәләрне бар кылган бөек илаһи Зат хакы өчен сорыйм: тыңлагыз әле мине зур игътибар белән! Шушы сулык өстендә тагын бер дөнья – җир тормышы барлыгын сезгә инде сөйләгән идем! Белеп торыгыз: кайвакыт елгабызда пәйда була торган тәмле, бөтенебезне кызыктырып ымсындырган җимнәр – ул теге мин әйткән дөньяда яшәүче Кеше дигән затның мәкерле хәйләсе! Берүк якын килмәгез шул ымсындыргыч җимнәргә! Юкса шул зат сезне эләктереп алып, утлы табага салып кыздырачак! Алдана күрмәгез, сак булыгыз, Аллаһы Тәгалә биргәннәренә риза булып, булганына шөкер итеп яшәгез!

Әмма үзе шаһит булган бу имәнеч күренештән каушап, калтыранып торган бака, шулай ихластан борчылуын белдерсә дә, балыкларның күбесе аңа ышанмый һәм янә: «Әйдә, үз юлыңда бул!» – дип мыгырдашып, еракта әйләнгәләп, ялтырап-җемелдәп торган аппетитлы җимгә таба бер-берсен җитез узарга тырышып юнәлә. Аяныч нәтиҗәсе исә озак көттерми: чиләк, учак, кызган утлы таба...

* * *

**КЫСКАЧА НӘСЫЙХӘТ:**

Бу әкият булса да, аның эчтәлегендә – зур гыйбрәт. Дөрестән дә, Адәм балаларының шактые бу кыйссадагы балыклардан әллә ни ары китмәгән. Кайсы берәүгә: «Бу дөнья тормышыннан соң безне ахирәт тормышы көтә! Әгәр нәфесләнеп, оялу хисен онытып хәрам булган нәрсәләргә үрелсәң, төрле «җим» рәвешендәге алдавыч ләззәтләрне татып карыйм дип Яратучыбыз Аллаһы Тәгалә билгеләп куйган чикләрне бозсаң, бу дөнья тормышыннан соң киләчәк ахирәт тормышында кызу утлы табада куырылып пешәчәгеңне белеп тор!» – дисәң, ул чыраен сытып: «Әйдә, бар, үз юлыңда бул, мин үзем беләм ничек яшәргә!» – дип җавап кайтара, яисә сүзне читкә борып, шушы сөйләшүне туктатырга тырыша.

Менә шулай... Бик татлы тоелган җимгә алданып, балыклар ниндидер күзгә күренмәгән көч илә кинәт өскә чөелеп билгесезлектә юк булып барган кебек, Адәм балалары да бер көнне җаннары белән хушлашып, «ахирәт» дигән билгесезлектә югала, ә аларны шунда озаткannар тиешле нәтиҗә ясамый һәм: «Болар кая китте икән?» – дигән сорауга җавап табуны кирәккә санамый. Чөнки җир йөзендәге вакытлыча тормыштан соң мәңгелек ахирәт тормышы булачагына ышанмый.

Ә син ышанасыңмы соң? Юк? Алайса, бу гыйбрәтле кыйссаны яңадан укы!

■ **Ришат хәзрәт Курамшин, Кукмара мәдрәсәсе мөдире**

**Хөрмәтле радиотыңлаучылар!**

"Азан" радиосы сайтының адресы үзгәрде. Хәзер безне azan.fm сылтамасы буенча таба аласыз. Иске мобиль кушымталар да үз эшен туктатты, аларны яңарту кирәк. Моның өчен, айфоннарда – App Store, андроидларда Play Market’ка кереп, "Азан радиосы" дип җыеп, "обновить" төймәсенә басарга кирәк. (Әгәр моңарчы телефоныгызда безнең кушымта булмаса, бер дә шикләнмичә куегыз). Әзер! Хәзер сез кая гына барсагыз да, бернинди түләүсез рәхәтләнеп татарча дини радио тыңлый аласыз.

**Сайт:** azan.fm
**Инстаграм:** azan.fm
**Вконтакте:** azanfm
**Телеграм-канал:** azanfm
**Почта:** radio@azan.fm
**Тел.:** 8 (843) 598-09-43

**QR – кодлар:**

Android өчен:

iPhone өчен:

ДҮШӘМБЕ, СИШӘМБЕ, ЧӘРШӘМБЕ, ПӘНҖЕШӘМБЕ, ШИМБӘ, ЯКШӘМБЕ

0:00-5:59 Коръән
6:00-6:20 Коръән тәфсире
6:30-6:32 Көндәлек догалар
6:40-6:50 Таян Аллаһка
6:55-7:00 Хәзрәткә сорау
7:05-7:15 Иман тәме
7:20-7:23 Миллият сүзлеге
7:30-7:35 Гыйбрәтле кыйссалар
7:40-7:45 Әд-дин вә әдәп
8:10-8:17 Шәхесләргә шәрехләр
8:25-8:40 Сак булыгыз! Секталар!
9:00-9:15 Күңелдән күңелгә
9:25-9:35 Тынычлык тәгълиматы
9:45-9:55 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.)
10:00-10:15 Бәхет тулы йорт
10:20-10:25 Гыйбадәттә сәгадәт
10:30-10:45 101 вәгазь
10:55-10:57 Көндәлек догалар
11:00-11:15 40 хәдис
11:25-11:28 Миллият сүзлеге
11:40-11:50 Намаз дәресләре
12:00-12:04 Азан
12:30-14:00 Кәлам Шәриф – мәгънәви тәрҗемә
14:05-14:15 Пәйгамбәрләр тарихы
14:20-14:27 Мәчетләребез тарихы
14:30-14:40 Сөннәт юлы
14:45-14:50 Әд-дин вә әдәп
14:55-15:10 Әбү Хәнифә (р.г.)
15:15-15:20 Хәзрәткә сорау
15:25-15:30 Әхлак баскычлары
15:45-15:48 Миллият сүзлеге
16:00-16:20 Коръән тәфсире
16:25-16:27 Көндәлек догалар
16:30-16:40 Таян Аллаһка
16:50-17:00 Иман тәме
17:05-17:08 Миллият сүзлеге
17:10-17:15 Гыйбрәтле кыйссалар
17:20-17:25 Әд-дин вә әдәп
17:50-17:57 Шәхесләргә шәрехләр
18:00-18:15 Сак булыгыз! Секталар!
18:30-18:45 Күңелдән күңелгә
18:50-19:00 Тынычлык тәгълиматы
19:05-19:15 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.)
19:20-19:35 Бәхет тулы йорт
19:40-19:45 Гыйбадәттә сәгадәт
19:50-20:05 101 вәгазь
20:10-20:15 Көндәлек догалар
20:20-20:35 40 хәдис
20:40-20:43 Миллият сүзлеге
20:45-20:55 Намаз дәресләре
21:00-21:03 Нәниләргә нәсыйхәт
21:20-21:30 Пәйгамбәрләр тарихы
21:40-21:47 Мәчетләребез тарихы
21:50-21:55 Хәзрәткә сорау
22:00-22:10 Сөннәт юлы
22:15-22:20 Әд-дин вә әдәп
22:25-22:40 Әбү Хәнифә (р.г.)
22:45-22:50 Әхлак баскычлары
22:55-22:58 Миллият сүзлеге
23:00-5:59 Коръән

ҖОМГА

0:00-5:59 Коръән
6:00-6:20 Коръән тәфсире
6:30-6:32 Көндәлек догалар
6:40-6:50 Таян Аллаһка
6:55-7:00 Җомга тәбриге
7:05-7:15 Иман тәме
7:20-7:23 Миллият сүзлеге
7:30-7:35 Гыйбрәтле кыйссалар
7:40-7:45 Әд-дин вә әдәп
8:10-8:17 Шәхесләргә шәрехләр
8:25-8:40 Сак булыгыз! Секталар!
8:50-8:55 Җомга тәбриге
9:00-9:15 Күңелдән күңелгә
9:25-9:35 Тынычлык тәгълиматы
9:45-9:55 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.)
10:00-10:15 Бәхет тулы йорт
10:20-10:25 Гыйбадәттә сәгадәт
10:30-10:45 101 вәгазь
10:55-10:57 Көндәлек догалар
11:00-11:15 40 хәдис
11:25-11:28 Миллият сүзлеге
11:30-11:35 Җомга тәбриге
11:40-11:50 Намаз дәресләре
12:00-12:04 Азан
12:30-14:00 Кәлам Шәриф – мәгънәви тәрҗемә
14:05-14:15 Пәйгамбәрләр тарихы
14:20-14:27 Мәчетләребез тарихы
14:30-14:40 Сөннәт юлы
14:45-14:50 Әд-дин вә әдәп
14:55-15:10 Әбү Хәнифә (р.г.)
15:15-15:20 Җомга тәбриге
15:25-15:30 Әхлак баскычлары
15:45-15:48 Миллият сүзлеге
16:00-16:20 Коръән тәфсире
16:25-16:27 Көндәлек догалар
16:30-16:40 Таян Аллаһка
16:50-17:00 Иман тәме
17:05-17:08 Миллият сүзлеге
17:10-17:15 Гыйбрәтле кыйссалар
17:20-17:25 Әд-дин вә әдәп
17:50-17:57 Шәхесләргә шәрехләр
18:00-18:15 Сак булыгыз! Секталар!
18:30-18:45 Күңелдән күңелгә
18:50-19:00 Тынычлык тәгълиматы
19:05-19:15 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.)
19:20-19:35 Бәхет тулы йорт
19:40-19:45 Гыйбадәттә сәгадәт
19:50-20:05 101 вәгазь
20:10-20:15 Көндәлек догалар
20:20-20:35 40 хәдис
20:40-20:43 Миллият сүзлеге
20:45-20:55 Намаз дәресләре
21:00-21:03 Нәниләргә нәсыйхәт
21:20-21:30 Пәйгамбәрләр тарихы
21:40-21:47 Мәчетләребез тарихы
21:50-21:55 Хәзрәткә сорау
22:00-22:10 Сөннәт юлы
22:15-22:20 Әд-дин вә әдәп
22:25-22:40 Әбү Хәнифә (р.г.)
22:45-22:50 Әхлак баскычлары
22:55-22:58 Миллият сүзлеге
23:00-5:59 Коръән

* Тапшырулар арасында эфирда кыска хәдисләр, нәшидләр һәм мөнәҗәтләр яңгырый



## ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты «Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә» басмасын яңа форматта нәшер итте

Сезнең игътибарыгызга «Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә» китабының яңа форматын тәкъдим итәбез. Биредә Корънәннең мәгънәви тәрҗемәләре генә урын алган. Шрифты үзгәртелеп бирелгән басма күпсанлы укучыларыбыз теләге белән нәшер ителде. Әлеге «Кәлам Шәриф»не уку бигрәк тә олы буын вәкилләре өчен уңайлы булыр дип өметләнәбез.

Изге Китабыбызны «Хозур» нәшрият йорты кибетләрендә сатып алырга һәм җир йөзенең теләсә кайсы почмагыннан интернет аша заказ бирергә мөмкин.

**Кибет:** Казан шәһ., Тукай ур., 36нчы йорт.

**Тел.:** +7 (960) 072-74-63

**Склад:** Казан шәһ., Газовая ур., 14нче йорт.

**Тел.:** +7 (966) 250-00-09

**Интернет-кибет:** huzurshop.ru (https://huzurshop.ru/)



## « Дин вә мәгыйшәт» газетасына 2020 елның икенче яртыеллыгына язылу башланды

- Ярты елга язылу бәясе: 156 сум
- Газета айга бер тапкыр чыга
- Язылу индексы: П4333

Түбәндәге сайтларда да язылу мөмкин: podpiska.pochta.ru һәм uslugi.tatarstan.ru сайтының «Подписка» бүлегендә.

дин вә мәгыйшәт

Белешмәләр өчен телефон: +7 (843) 598 09 42

### КАЗАН ӨЧЕН СЕНТЯБРЬ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Сәхәр тәмам/ иртәнге намаз | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы/ ифтар | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 01.09.2020 | 03:18 | 04:48 | 12:00 | 16:22 | 18:36 | 20:31 |
| 02.09.2020 | 03:20 | 04:50 | 12:00 | 16:20 | 18:34 | 20:27 |
| 03.09.2020 | 03:22 | 04:52 | 12:00 | 16:18 | 18:31 | 20:24 |
| 04.09.2020 | 03:24 | 04:54 | 12:00 | 16:16 | 18:29 | 20:21 |
| 05.09.2020 | 03:26 | 04:56 | 12:00 | 16:14 | 18:26 | 20:17 |
| 06.09.2020 | 03:28 | 04:58 | 12:00 | 16:12 | 18:24 | 20:14 |
| 07.09.2020 | 03:30 | 05:00 | 12:00 | 16:10 | 18:21 | 20:11 |
| 08.09.2020 | 03:32 | 05:02 | 12:00 | 16:08 | 18:18 | 20:08 |
| 09.09.2020 | 03:33 | 05:03 | 12:00 | 16:06 | 18:16 | 20:05 |
| 10.09.2020 | 03:35 | 05:05 | 12:00 | 16:04 | 18:13 | 20:01 |
| 11.09.2020 | 03:37 | 05:07 | 12:00 | 16:02 | 18:10 | 19:58 |
| 12.09.2020 | 03:39 | 05:09 | 12:00 | 16:00 | 18:08 | 19:55 |
| 13.09.2020 | 03:41 | 05:11 | 12:00 | 15:58 | 18:05 | 19:52 |
| 14.09.2020 | 03:43 | 05:13 | 12:00 | 15:55 | 18:03 | 19:49 |
| 15.09.2020 | 03:45 | 05:15 | 12:00 | 15:53 | 18:00 | 19:46 |
| 16.09.2020 | 03:47 | 05:17 | 12:00 | 15:51 | 17:57 | 19:43 |
| 17.09.2020 | 03:49 | 05:19 | 12:00 | 15:49 | 17:55 | 19:40 |
| 18.09.2020 | 03:51 | 05:21 | 12:00 | 15:47 | 17:52 | 19:37 |
| 19.09.2020 | 03:53 | 05:23 | 12:00 | 15:45 | 17:49 | 19:34 |
| 20.09.2020 | 03:55 | 05:25 | 12:00 | 15:42 | 17:47 | 19:31 |
| 21.09.2020 | 03:57 | 05:27 | 12:00 | 15:40 | 17:44 | 19:28 |
| 22.09.2020 | 03:59 | 05:29 | 12:00 | 15:38 | 17:41 | 19:25 |
| 23.09.2020 | 04:01 | 05:31 | 12:00 | 15:36 | 17:39 | 19:22 |
| 24.09.2020 | 04:02 | 05:32 | 12:00 | 15:33 | 17:36 | 19:19 |
| 25.09.2020 | 04:04 | 05:34 | 12:00 | 15:31 | 17:34 | 19:16 |
| 26.09.2020 | 04:06 | 05:36 | 12:00 | 15:29 | 17:31 | 19:13 |
| 27.09.2020 | 04:08 | 05:38 | 12:00 | 15:27 | 17:28 | 19:10 |
| 28.09.2020 | 04:10 | 05:40 | 12:00 | 15:24 | 17:26 | 19:08 |
| 29.09.2020 | 04:12 | 05:42 | 12:00 | 15:22 | 17:23 | 19:05 |
| 30.09.2020 | 04:14 | 05:44 | 12:00 | 15:20 | 17:20 | 19:02 |

**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**
*Август саны, №8 (301)*

Баш мөхәррир: **Нәширбанов И.К.**
Мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН;**
ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБАРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2752
Газетага ярты елга язылу бәясе – 156 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 25 нче августта таратыла.
График буенча бу санга 24 нче август көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.